**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**20 ноябрь 2021 ел** **№ 3**

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Шәпше авыл җирлегенең Шәпше торак пукты халык җыеннары нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 2131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 нчы маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 нче маддәсе нигезендә 2021елның 18 ноябрендә, 2021елның 19 ноябрендә, 2021елның 20 ноябрендә 18.00 сәгатьтә «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Шәпше авыл җирлегенең Шәпше торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2022 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым акчаларын кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?» мәсьәләсе буенча халык җыены нәтиҗәләре беркетмәсе төзелде:

а) Шәпше авылы зиратын киртәләп алу, смета һәм килешү буенча түләү;

б) Шәпше авылында янгын гидрантларын урнаштыру өчен гидрантлар сатып алу, смета һәм килешү буенча эшләр өчен түләү;

в) МТЗ-82 тракторына асылмалы җиһазлар сатып алу.

«ӘЙЕ» «КАРШЫ».

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 997 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны -548, бу 54,9% тәшкил итә

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

халык җыенында 539 катнашучы «ӘЙЕ» позициясе өчен тавыш бирде;

җыенда катнашкан 9 кеше «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1.Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Шәпше авыл җирлегенең Шәпше авыл җирлегендә халык җыенын узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. . 2022 елда Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Шәпше авыл җирлегенең Шәпше торак пункты территориясендә даими яшәүче һәм яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

Экономияләнгән акчаны Шәпше авыл җирлеге башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен тотарга рөхсәт итәргә.

3. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә) http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ Фәрит Мөхәммәтшин «Бердәм Россия» Бөтенроссия сәяси партиясенең Татарстан төбәк бүлеге сәяси советы утырышын уздырды http://pravo.tatarstan.ru/

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Шәпше авыл җирлеге башлыгы В.А.Беляков